| | |
|---|---|
| **ГЛАВА СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТӘРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.11. 2021 ел. Иске Тәрбит авылы №2

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Иске Тәрбит авыл җирлеге
Иске Тәрбит авылында
үзара салым кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында .

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 28.07.2004 ел, № 45-ЗР Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп ярашлы рәвештә карар бирәм:

1. 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы К.Маркс урамы , 8нче йорт янында һәм Иске Тәрбит авылы Үзәк урамы, 25 нче йорт яныныда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыенның беренче этабын билгеләргә.
2. 2021 елның 26 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы Ленина урамы 17нчы йорт янында һәм Иске Тәрбит авылы Уральская урамы 6нчы йорт янында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике җыенның икенче этабын билгеләргә.
3. 2021 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка һәм 12 сәгать 00 минутка Иске Тәрбит авылы МФЦ бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге Иске Тәрбит авылында

үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар ике жыенның өченче этабын билгеләргә.

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Иске Тәрбит авыл җирлегенең Иске Тәрбит авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге торак пунктларындагы санкцияләнгән һәм санкцияләнмәгән чүплекләр территорияләрен чистарту;

б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- материаллар сатып алып, су челтәрләрен ремонтлау;
- материаллар сатып алып, су башнясы павильоннарын ремонтлау;

в) җирлектәге торак пунктлар чикләрендәге җирле автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ;
- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- җирлектәге торак пунктлар чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

г) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- зиратларны чистарту һәм төзекләндерү,

"риза" "каршы"

3. Әлеге карарны Иске Тәрбит авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Кайбыч муниципаль районы Иске Тәрбит авыл җирлеге башкарма комитетына Иске Тәрбит авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәргәндә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларын таралуын кисәтү өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Тәрбит авыл җирлеге башлыгы В.Г. Тимофеев